КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1341

Милли үзенчәлекне саклау, милли (туган) телне һәм милли мәдәниятне үстерү, төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту һәм үстерү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга аларның матди-техник базасын ныгытуга һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар иҗат коллективларының матди-техник базасын ныгытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Милли үзенчәлекне саклау, милли (туган) телне һәм милли мәдәниятне үстерү, төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту һәм үстерү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга аларның матди-техник базасын ныгытуга һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар иҗат коллективларының матди-техник базасын ныгытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.

3. Бу карар (Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 29 пунктыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 30 декабрь, 1341 нче
карары белән расланды

Милли үзенчәлекне саклау, милли (туган) телне һәм милли мәдәниятне үстерү, төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту һәм үстерү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга аларның матди-техник базасын ныгытуга һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар иҗат коллективларының матди-техник базасын ныгытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм милли үзенчәлекне саклау, милли (туган) телне һәм милли мәдәниятне үстерү, төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту һәм үстерү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерциягә карамаган оешмаларга (алга таба – коммерциягә карамаган оешмалар) аларның матди-техник базасын ныгытуга һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар иҗат коллективларының матди-техник базасын ныгытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Министрлык.

4. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган расходлар (чыгымнар) юнәлешләренә төп чараларны сатып алу керә, шул исәптән:

музыкаль инструментлар сатып алу;
костюмнар сатып алу;
тавыш җиһазлары сатып алу;
җиһаз сатып алу;
компьютер техникасы сатып алу;

офис җиһазлары сатып алу.

5. Субсидия бирү өчен коммерциягә карамаган оешманы сайлап алу (алга таба – сайлап алу), коммерциягә карамаган оешманың сайлап алу критерийларына туры килү-килмәвеннән һәм сайлап алуда катнашуга тәкъдимнәр (заявкалар) керү чиратыннан чыгып, коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан сайлап алуда катнашуга җибәрелгән тәкъдимнәр (заявкалар) (алга таба – заявка) сорату юлы белән гамәлгә ашырыла.

6. Сайлап алу критерийлары:

коммерциягә карамаган оешма үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

коммерциягә карамаган оешманың устав эшчәнлеге юнәлеше – милли үзенчәлекләрне саклау, милли (туган) телне һәм милли мәдәниятне үстерү, төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту һәм үстерү өлкәсендә эшчәнлек гамәлгә ашыру.

7. Субсидияләр турында мәгълүматлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын) формалаштырганда «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.

8. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://mincult.tatarstan.ru) (алга таба – рәсми сайт), заявкалар кабул ителә башлау көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп урнаштырыла:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасы (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән субсидияне бирү максатларын;

ирешү өчен әлеге Тәртипнең 20 пунктында каралган субсидия бирү нәтиҗәсен (алга таба – субсидия бирү нәтиҗәсе);

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) битләр күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 9 пункты нигезендә коммерциягә карамаган оешмаларга карата таләпләрне һәм коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 10 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 13 – 17 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

коммерциягә карамаган оешмаларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләрен аңлату тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогын;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

бердәм порталда һәм рәсми сайтта сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы, ул сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң булмаска тиеш.

9. Коммерциягә карамаган оешмага, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1 нче көненә түбәндәге таләпләргә туры килсә, сайлап алуда катнашырга рөхсәт ителә:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау;

үзгәртеп оештыру (коммерциягә кармаган оешмага башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, коммерциягә кармаган оешманың эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки коммерциягә карамаган оешманың баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмау;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы расланган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 процентган артмаган Россия юридик заты булмау;

бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмау;

10. Сайлап алуда катнашу өчен коммерциягә карамаган оешма Министрлыкка бу Тәртипнең кушымтасында бирелгән формада заявка кертә, аңа түбәндәгеләр кирә:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә коммерциягә карамаган оешма турында, аның тарафыннан бирелә торган заявка турында мәгълүмат, сайлап алу үткәрүгә бәйле коммерциягә карамаган оешма турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык;

коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле зат тарафыннан расланган коммерциягә карамаган оешманың гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга үзгәрешләр кертү турында документлар күчермәләре (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә күчермәсен теркәп);

чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта – бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга чыгымнарның коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан расланган сметасы;

чыгымнарны каплауга субсидия бирелгән очракта – коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга чыгымнарны гамәлгә ашыруга бәйле сарыф ителгән факттагы чыгымнарны раслый торган документлар күчермәләре (коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле зат тарафыннан расланган чыгымнар сметасы, шартнамәләр һәм аларның кушымталары, башкарылган эшләр (күрсәтелгән хезмәтләр) актлары, түләү йөкләмәләре, шулай ук (булганда) счетлар, счет-фактуралар, керем һәм чыгым ордерлары, накладнойлар (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә күчермәсен теркәп));

салым органының сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү урнаштырыла торган айга кадәрге айның 1 нче көненә карата салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган белешмә кәгазе;

коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан имзаланган, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1 нче көненә карата субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлар, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлар булмау турында гарантия хаты;

коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан имзаланган, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1 нче көненә карата коммерциягә карамаган оешманың үзгәртеп оештыру (коммерциягә карамаган оешманы башка юридик затка кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәвен һәм коммерциягә карамаган оешманың эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын раслый торган гарантия хаты;

коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан имзаланган, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1 нче көненә карата дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган

башкарма орган функциясен үтәүче зат яки коммерциягә карамаган оешманың баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмавын раслый торган гарантия хаты;

коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан имзаланган, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1 нче көненә карата коммерциягә карамаган оешманың чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы расланган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмавын раслый торган гарантия хаты;

коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан имзаланган, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1 нче көненә карата коммерциягә карамаган оешманың бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавын раслый торган гарантия хаты.

Коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бу пунктның алтынчы абзацында каралган документ тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документны салым органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Заявка һәм аңа теркәлә торган документлар бер папка (том) итеп тегелгән, һәр бите номерланган, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесенең үз кулы белән имзасы куелган һәм мөһер белән таныкланган булырга тиеш.

Һәр документ төгәл итеп басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр (коммерциягә карамаган оешма җитәкчесенең үз кулы белән куелган имзасы белән расланган һәм мөһер сугылган төзәтмәләрдән тыш) рөхсәт ителми.

11. Бер коммерциягә карамаган оешма бер генә заявка бирергә мөмкин.

12. Министрлык заявканы кергән көнне, керү датасын һәм вакытын күрсәтеп, кабул итә һәм терки.

13. Заявкаларны карап тикшерү максаты белән Министрлык тарафыннан заявкаларны карап тикшерү буенча алты кешедән торган комиссия (алга таба – Комиссия) төзелә. Комиссия составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына Министрлык хезмәткәрләре арасыннан Комиссия рәисе һәм әгъзалары керә.

Комиссия эше аның утырышларында башкарыла. Әгәр утырышта Комиссия әгъзаларының гомуми санының яртысыннан күбрәге катнашса, утырыш тулы хокуклы дип санала.

Заявкалар кабул итү срогы тәмамланган көннән соң килә торган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Комиссия коммерциягә карамаган оешма тарафыннан тәкъдим ителгән заявканың һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның керү чираты нигезендә карап тикшерелә, шулай ук коммерциягә карамаган оешманың бу Тәртипнең 6 һәм 9 пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килүен билгели.

Заявкаларны һәм аларга теркәлгән документларны карап тикшерү йомгаклары турында Комиссия карарлары Комиссиядә катнашучыларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

Заявкаларны карау нәтиҗәләре Комиссия утырышы беркетмәсе (алга таба – беркетмә) белән рәсмиләштерелә, аңа Комиссия әгъзалары кулын куя һәм Комиссия утырышы үткәрелгән көнне Министрлыкка тапшырыла.

14. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен нигезләр:

коммерциягә карамаган оешманың бу Тәртипнең 6 һәм 9 пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килмәве;

тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә заявкаларга карата билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

заявкалар бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң заявка бирү;

бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау.

15. Министрлык беркетмә нигезендә сайлап алуда җиңүчене билгели һәм беркетмәгә кул куелганнан соң 10 көн эчендә сайлап алуда җиңүчегә субсидия бирү турында карар кабул итә. Министрлык карары боерык белән рәсмиләштерелә.

16. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән коммерциягә карамаган оешмага (алга таба – субсидия алучы) субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 10 нчы пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү.

17. Сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат, сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган өченче календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм рәсми сайтта урнаштырыла, түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

18. Субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = P_1 + P_2 + P_3 + P_4 + P_5 + P_6,$$

монда:
$P_1$ – музыкаль инструментлар сатып алу;
$P_2$ – костюмнар сатып алу;
$P_3$ – тавыш җиһазлары сатып алу;
$P_4$ – җиһазлар сатып алу;
$P_5$ – компьютер техникасы сатып алу;
$P_6$ – офис җиһазлары сатып алу.

Бу пунктта күрсәтелгән юнәлешләр буенча расходлар (чыгымнар) Россия Федерациясе законнары нигезендә, шулай ук бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә.

19. Субсидия бирү Министрлык һәм субсидия алучы арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максат өчен финанс белән тәэмин итү (каплау) чыганагы субсидияләр булган расходларның (чыгымнарның) юнәлешләре;

субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләре;

субсидия күчерү тәртибе;

чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта – субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында һәм финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында, шулай ук, кирәк булганда, өстәмә хисап бирү хакында хисап бирү сроклары һәм формалары;

чыгымнарны каплауга субсидия бирелгән очракта – субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисаплар, шулай ук кирәк булганда өстәмә хисаплылык бирү сроклары һәм формалары;

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, Министрлык тарафыннан субсидиянең калган өлешен файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгәндә, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шартлар;

чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта – субсидия алучының, шулай ук субсидия алучылар (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, үзләренең устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый

берәмлекләр катнаша торган хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнаша торган коммерцияле оешмалардан тыш) белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның аларга карата Министрлык тарафыннан тикшерү үткәрүгә һәм дәүләт финанс контроле органы тарафыннан субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәүгә карата муниципаль финанс контролен башкаруга ризалыгы;

бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешә алмаганда килешүне өзү хакында шарт;

субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык чаралары;

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турында нигезләмәләр.

Министрлык, кирәк булганда, субсидия алучы белән Татарст ан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

20. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе – субсидия алучының матди-техник базасын ныгыту һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар иҗат коллективларының матди-техник базасын ныгыту максатларында бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча сатып алынган төп чаралар саны (кимендә бер берәмлек күләмендә).

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү сроклары – субсидия бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, Министрлык тарафыннан бу Тәртипнең 25 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән очракта, килешүдә билгеләнә торган субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү сроклары субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 31 декабреннән дә соңрак билгеләнә алмый.

21. Субсидия, Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында субсидия алучы ачкан исәп-хисап яки корреспондентлык счетына бер тапкыр күчерелә.

22. Субсидия алучыга, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затларга чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчаларын сатып алу тыела.

23. Субсидия алучы субсидия керү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

24. Субсидия чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен бирелгән очракта, субсидия алучы Министрлыкка субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

Субсидия чыгымнарны каплау өчен бирелгән очракта, субсидия алучы Министрлыкка субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыра.

Хисаплар, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 нче көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләгән килешүләрнең бертип формаларына теркәлә торган формалар буенча кертелә.

Кирәк булганда Министрлык килешүдә субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү срокларын һәм формаларын билгели.

25.Ссубсидия чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен бирелгән очракта, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калган өлеше булганда, субсидия алучы, хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр, Министрлыкка әлеге акчага ихтыяҗ булуны нигезли торган документларны тапшыра.

Министрлык субсидия алучыдан әлеге документларны алган көннән 15 көн эчендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, субсидия алучының әлеге акчага ихтыяҗы булу турында яки аларга ихтыяҗ булмаганда әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтару хакында карар кабул итә.

26. Субсидия алучының хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешенә ихтыяҗы булу турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелгән карар булмаган очракта, субсидия алучы әлеге акчаны хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарырга тиеш.

27. Министрлык тарафыннан хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешенә субсидия алучының ихтыяҗы булу турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелгән карары булган очракта, субсидия алучы финанс белән тәэмин итү чыганагы булып әлеге акча торган чыгымнарны бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга тотарга хокуклы.

28. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

29. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү фактын чагылдыра торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүгә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча мониторинг үткәрә.

30. Субсидия Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы һәм (яисә) субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затлар тарафыннан субсидияләр бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар, максатлар һәм тәртип бозылган очракта;

субсидия бирү нәтиҗәсенең ирешелмәгән һәр күрсәткече өчен 5 процент күләмендә – субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешмәгән очракта.

31. Субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 26 һәм 30 пунктларында билгеләнгән субсидияне ирекле кире кайтару срогы бозылган очракта, Министрлык әлеге срок тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри түләтү буенча чаралар күрә.

32. Субсидияләрне максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Милли үзенчәлекне саклау, милли (туган) телне һәм милли мәдәниятне үстерү, төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту һәм үстерү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга аларның матди-техник базасын ныгытуга һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар иҗат коллективларының матди-техник базасын ныгытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

Форма

_______________________________________________________________________________
______________________________ га бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирүгә
заявка

20__ел, «__» __________

1. Коммерциягә карамаган оешманың тулы исеме: ____________________________
___________________________________________________________ (алга таба – оешма)
2. Оешма гамәлгә ашыра торган эшчәнлек төрләре турында мәгълүмат:
_______________________________________________________________________________
3. Субсидия бирү максатлары: ______________________________________________
_______________________________________________________________________________
4. Субсидия суммасы: _____________________________________________________
5. Оешманың урнашкан урыны: ______________________________________________
6. Оешманың почта адресы: ________________________________________________
7. Субсидия акчасын күчерү өчен оешманың банк реквизитлары: _________
_______________________________________________________________________________

Моның белән заявкада бирелгән барлык мәгълүмат, шулай ук өстәмә материаллар ышанычлы, дип белдерәм.

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә оешма турында, аның тарафыннан бирелә торган заявка турында мәгълүмат, сайлап алу үткәрүгә бәйле оешма турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык бирәм.

Кушымта:

| Т/с | Теркәлгән документларның исеме | Битләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

Оешма җитәкчесе __________________/_________________________
(имза) (имзаны таркатып язу)

М.У.

________________________________